**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 март № 135

г. Казань

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Ф.Г.Вәлиевның бадминтон буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында

Балалар һәм яшүсмерләр арасында физик культура һәм массакүләм спортны үстерү, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бадминтон буенча җыелма командаларына спорт резервын әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Ф.Г.Вәлиевның бадминтон буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә, аның төп эшчәнлек максаты итеп Татарстан Республикасында бадминтонны үстерүне билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

60 көн эчендә Учреждениенең уставын расларга һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә башка кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

Учреждениенең уставын раслаганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәт исемлеген кертергә;

ел саен Учреждениенең уставында күздә тотылган төп эшчәнлек төре нигезендә Учреждениегә дәүләт йөкләмәсен расларга;

үз норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение уставын раслаганнан соң 30 көн эчендә Учреждениегә оператив идарә

хокукында аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен билгеләнгән тәртиптә беркетергә.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының спорт юнәлеше өлкәсендәге дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә күздә тотылган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла;

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә, Учреждение уставын раслаганнан соң 60 көн эчендә физик һәм (яки) юридик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Учреждение мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

6. Бу карарның үтлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\135.docx